БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__28__» ___08____ 2020 ел № _267____

**Үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару системалары өчен гарантияләүче оешманы һәм аның эшчәнлек зонасын билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә җылылык белән, су белән өзлексез тәэмин итүне һәм ташландык суларны өзлексез чыгаруны оештыру максатларында, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның 6, 11, 12 статьялары, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару системалары өчен гарантияләүче оешма итеп «Управление» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьне билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару системалары өчен гарантияләүче оешма итеп «Торак-коммуналь хуҗалыкның Чепья күптармаклы җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьне билгеләргә.

3. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов